ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН», МЭР ГОРОДА ЛЕНИНОГОРСКА

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МЭРЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

11.11.2021 г.Лениногорск № 104

Муниципаль милектәге дини оешмаларның дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында нигезләмәне раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, карар бирәм:

1. Муниципаль милектәге дини оешмаларның дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында нигезләмәне расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Лениногорск муниципаль районы Башлыгы урынбасары С.В. Тимаковка йөкләргә.

«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы
вазифаларын башкаручы С.В. Тимаков

И.Р. Хәйбрахманов
2-44-72

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2021 елның 11 ноябрендәге 104 номерлы карары белән расланды

## Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә Муниципаль милектәге дини оешмаларның дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмалар гаризасын караганда килеп туа торган сораулар буенча комиссияне төзү һәм эшчәнлеге тәртибен билгели (алга таба – Комиссия).

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, указлар һәм Россия Федерациясе Президенты карарлары һәм боерыклары, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары һәм боерыклары һәм Татарстан Республикасы Президенты указлары һәм боерыклары, ТР Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә нигезләнә.

Комиссиянең компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлар, вәкиллекле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә дини оешмаларга муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

Вәкиллекле орган - «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге «Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе.

2. Комиссия карарларны түбәндәге сораулар буенча кабул итә:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында дини оешмалар гаризасын караганда килеп туа торган каршылыкларны җайлау.

Дини оешмага дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә физик һәм юридик затларның хокукларын һәм (яки) законлы мәнфәгатьләрен бозу мөмкинлекләре яисә дини оешма гаризасын карауга бәйле рәвештә, вәкиллекле органның гамәлләре (гамәл кылмавы) турында физик һәм юридик затларның гаризаларын карау.

3. Комиссия түбәндәге функцияләр үти:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан аңа йөкләнгән бурычларны үтәү өчен мәгълүмат соратып ала.

Үзенең утырышларында Татарстан Республикгсы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләрен, оешмалар һәм дин белеме, культурология, хокук һәм комиссия компетенциясенә кергән сораулар буенча башка өлкә белгечләрен тыңлый.

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы территориясендә дини оешмаларга үз компетенциясе чикләрендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру яки дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшырудан баш тарту турында вәкиллекле органга тәкъдимнәр белән нигезләнгән карар кабул итә.

4. Комиссия хокуклы:

Комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләрен, оешмалар һәм дин белеме, культурология, хокук һәм башка өлкә белгечләрен җәлеп итәргә.

Комиссия компетенциясенә кергән сорауларны карау өчен эшче төркемнәр төзергә.

6. Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия секретаре һәм иҗтимагый оешма вәкилләре, оешмалар һәм дин белеме, культурология, хокук һәм башка өлкә белгечләре керә. Кирәк булган очракта, комиссия составына Лениногорск районы җирле үзидарә органнарының башка вәкилләре керергә мөмкин.

Комиссия составы Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрыны карары белән раслана.

6.Комиссия эшчәнлеге белән комиссия рәисе җитәкчелек итә.

7.Комиссия утырышлары, әлеге Нигезләмәнең 2 пункты нигезендә комиссия карарын таләп итүче сораулар килеп чыккан саен үткәрелә.

Комиссия рәисе карары буенча комиссиянең күчмә утырышлары үткәрелә.

Комиссия утырышларын чакыру, үткәрү һәм аның тарафыннан кабул ителгән карарларның үтәлешен контрольдә тоту комиссия рәисенә йөкләнә.

8.Комиссия утырышы, әгәр анда әгъзаларның яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы булып санала. Комиссия әгъзасы утырышта катнашмаган очракта, каралучы сораулар буенча үз фикерен язмача формада бәян итү хокукына ия.

Комиссия карары утырышта катнашкан комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, ул рәис тарафыннан имзалана.

Комиссия әгъзаларының тавышы тигез булганда комиссия рәисенең тавышы хәлиткеч булып тора.

9. Комиссиянең компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлар, вәкиллекле органнар тарафыннан дини оешмаларга муниципаль милектә

булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

10. Әлеге карар белән килешмәгән комиссия әгъзаларының аерым фикере әлеге карарга кушымта буларак рәсмиләштерелә.

11.Әлеге карар белән килешмәгән комиссия карары, шулай ук комиссия әгъзаларының аерым фикере Интернет челтәрендә урнаштыру өчен 7 көн эчендә вәкиллекле органга җибәрелә.